*А.Ш. Зыятдинов*

## УЛ ЭШ КЕШЕСЕ ИДЕ

Мансур ага Хәсәнов белән мин озак еллар берьяклы гына таныш идем, ягъни, аны күреп таныйм, чыгышларын тыңлыйм, язганнарын укыйм һәм күңелемдә үзенә карата хөрмәт йөртәм, бу шәхес белән кызыксыну да арта бара. Ә ул мине белми. Очрашып танышу озак еллар насыйп булмады. Күрәсең, монда безнең туып-үскән яклар арасы ерак булу да – ул Кама аръягыннан, ә мин Казан артыннан – һәм яшь аермабызның зур булуы да үз ролен уйнагандыр. Аннан, Мансур абый гуманитар өлкә белгече, ә минем өлкә – техника, ул обком, кабмин вәкиле, ә мин – завод кешесе. Тормышымдагы рухи җитәкчем, гомерем буе җылы мөнәсәбәтләр саклап яшәгән кешем – бертуганым Бакый абый булды. Ул Мансур Хәсәновның яшьтәше иде һәм аның турында беренче мәгълүматларны да мин абыемнан алдым.

Бакый Зыятдинов районыбызның хөрмәтле педагогы, физик-математик, мәктәп директоры. Безнең як районнарының лекторы буларак Казанда партия өлкә комитеты яки Министрлар кабинеты оештырган төрле укуларда, семинарларда да булгалый. Шулар турында сөйләгәндә аның: «Хәсәнов та чыгыш ясады», – дип, аның чыгышларының бик төгәл, үтемле булуын ассызыклап әйтүе дә истә калган. Абыем тагын Хәсәновның репрессия еллары корбаннары буларак исемнәре халкыбыз хәтереннән җуела язган шәхесләребез мирасын ачыклап, үз чыгышларында аларның рухи дөньябызны баетуга керткән өлешләрен бәяли баруына хәйран кала иде.

Түбән Камада яши башлагач, язмыш мине университетта укыганда Мансур Хәсәновичның лекцияләрен тыңлаган, рухы белән чын педагог, шәһәребездәге педагогия көллияте директоры Рифкать Муллин белән очраштырды. Аның туган авылы Иштирәк Мансур Хәсәновның туган авылы Бигеш белән янәшә урнашкан. Мин Муллинның да Мансур ага турында җылы истәлекләрен еш ишеттем. Ул: «Мансур Хәсәнов Зәй төбәгенең Казандагы иң абруйлы кешесе», – дип әйтә иде.

Ә инде Мансур Хәсәнов шәхесенә карата иң әтрафлы бәяләмәләрне мин хөрмәтле аксакалыбыз – бөек рассамыбыз, сынлы сәнгатьтәге даһиебыз Бакый ага Урманче авызыннан ишеттем һәм аңлап куандым да: «Менә нинди эшлекле кешеләр бар икән безнең җитәкчелектә!» Һәм, табигый инде, күңелемдә бу бик тә үзенчәлекле шәхес белән танышу, аралашу теләге дә туды. Чөнки бу уйлар бөек Тукаебыз абруе, аның халкыбыз язмышында тоткан урынын лаеклы бәяләү һәм шул фикерне заман таләпләренә ярашлы итеп башкарып чыгу белән бәйләнгән иде.

Әйе, без бүген инде бөек шагыйребез хөрмәтенә корылган мәһабәт «Тукай-Кырлай»

комплексына һәм Казаныбызның Иске татар бистәсендә, затлы бинада урнашкан бай эчтәлекле Г. Тукай музеена ия халык. Димәк, без сөекле шагыйребезнең халкыбыз язмышында тоткан урынын да тиешле дәрәҗәдә бәяли беләбез һәм яшь буынны да шул рухта тәрбияләргә тырышабыз. Киләчәгебез өметле.

Ә бу комплексны салу һәм музейларны оештыру фикерен үз күңелендә йөрткән һәм җәмәгатьчелеккә җиткергән кеше – ул мөхтәрәм аксакалыбыз, Габдулла Тукайның замандашы, аннан 11 яшькә генә кече булган, үзен күреп белгән, иҗатына мөкиббән Бакый Идрис улы Урманче. Юк, идея авторы гына түгел, ә Кырлайдагы шундый зәвыклы музей бинасының һәм бай эчтәлекле комплексның архитекторы да. Шунысын да белеп торыйк: «Шамил йорты»н Тукай музеена бирдерү идеясе дә – Б. Урманченыкы.

Бу урында М. Хәсәновның «Сайланма хезмәтләр» исемле җыентыгындагы Б. Урманчега багышланган мәкаләсеннән өземтә китерү урынлы булыр. «Бакый Урманче гомере буена таланты белән дә, җаны белән дә, иҗатында да гел бөек Тукаебызга тартылды, идеяләре белән рухланды.

Аның Г.Тукайга бөек мәхәббәтен, шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын камил белүен мин 70–80 елларда Арча районы Тукай-Кырлайда шагыйрьнең музей комплексын төзегәндә аеруча нык тойдым... Ул Г. Тукай музей-йортының архитекторы булды. Тукай-Кырлай комплексын төзүдә Татарстан хөкүмәтенә зур ярдәм күрсәтте» (321 бит).

Шушы урында Бакый Урманченың, бу игелекле хезмәтләренә кадәр нинди фаҗигале тормыш юлы узганлыгын искә алмасак, бу затлы шәхескә карата беркатлылык, җиңел караш булыр иде. 1927 елда, халкыбыз мең ел файдаланган алфавитыбызны алыштыруга риза булмыйча, 82 зыялыбыз имза куеп Сталинга җибәргән хатта аның да кулы була. Ул шулар арасыннан Соловки лагерларын да үтеп исән калган өч бөртек кешенең берсе. Юк, алай гына да түгел, аннан соң «минус 38» исемендәге күрсәтмә нигезендә СССРның 38 шәһәрендә яшәүдән мәхрүм ителеп, Казаныбызга 62 яшен узгач кына кайта алганы, сынмаганы, рухын саклаганы... Ягъни Сталин вафатыннан соң, сәяси туңнар бераз җеби башлап, кирәге чыккач кына кайта алганы.

Рухи дөньябыз өчен шундый көчле, әзерлекле шәхесне саклаганы өчен язмышка без рәхмәтле булыйк.

Үзем өчен иң куанычлысы: Бакый ага Урманче белән безнең элемтәләр ныгый барды, гаилә дуслары булдык. Очрашулар ешайды, аларның һәрберсе безне аңарчы билгеле булмаган шәхесләр, мәгълүматлар белән таныштыра иде. Шушы рухи яктан бик бай, тарихи шәхес белән Түбән Кама халкын да таныштыру ниятеннән, шәһәребездә мөхтәрәм аксакалыбызның 90 еллыгына багышланган «Җидегән чишмә» кичәсе дә уздырдык. Онытылмаслык кичә булды ул. Бакый ага үзе дә ул кичәне: «Сез миннән хан ясадыгыз», – дип, шаяртып искә ала иде. Без Бакый

ага Урманче белән Тукай-Кырлайга да сәяхәт кылдык. Әлбәттә, максатым – бу тарихи шәхеснең үзеннән комплекс турында мәгълүмат алу, чөнки безнең буын яшьтән үк Пушкин, Лермонтов, Толстой... музей-йортлары, усадьба-утарлары турында мәгълүматлы иде. Без аны шулай булырга тиеш кебегрәк кабул итәргә күнеккән, чөнки алар югары катлам, «ничек инде усадьба-утарсыз булсын...» Ә менә үз гомерендә йорты түгел, фатиры да булмаган Тукаебызны да шундый затлы «комплекслы» итү – нинди матур, көчле идея бит ул. Мине шул идеянең барлыкка килү һәм тормышка ашыру тарихы кызыксындыра иде.

Бакый ага, гади генә: «Иң мөһиме кемнең нинди йортта үсүе түгел бит, ә тудырган иҗаты, үзләреннән соң калдырган хезмәтләренең кыйммәтендә, аларның бүгенге тормышыбыз өчен дә актуаль булуында. Ә безнең Тукаебызның иҗаты иң зур хөрмәткә лаек. Шушы хакыйкатьне Татарстан җитәкчелегеннән иң беренче булып Мансур Хәсәнов аңлады. Без башка җитәкчеләрдә дә теләктәшлек таптык. Иң мөһиме – обкомның беренче секретаре Фикрәт Табиевтан хуплау алдык», – дип төшендерде.

Димәк, Бакый ага Урманче бу комплексның идея җитәкчесе – төп архитектор. Ә Мансур Хәсәнов – башкарып чыгуны оештыручы, төп җитәкче. Бу – 1978 елда төзелә башлап, 1979 елның 25 апрелендә ачылган комплекс, мөгаен, аларның икесе өчен дә хезмәт елларыннан халкыбызга калдырылган иң күркәм, истәлекле бүләк буларак та каралырга лаеклыдыр.

Әлеге комплекс турында сүз чыкканда Бакый аганың йөзе балкып китә иде. Ә урман хуҗалыгы хезмәткәрләренең ничек булышуларын, Арча районы җитәкчеләренең бу эшкә нинди җаваплылык белән карауларын һәм Казан арты – Арча районы балта осталарының ничек тырышып, булсынга эшләүләрен зур канәгатьлек хисе белән искә алулары әле дә хәтеремдә.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 100 еллык юбилее халкыбыз һәм күпсанлы, мәртәбәле кунаклар өчен чын мәгънәсендә куанычлы, зур масштаблы бәйрәм булды. Аның да төп бизәге – Кырлайда махсус төзелгән өр-яңа музей-комплекс иде. Ул шагыйрьгә халкыбыз рәхмәте буларак кабул ителде. Ә инде бу гүзәл корылманы барлыкка китерү өчен зур күңел байлыкларын, тырышлыкларын куйган ике шәхес: Бакый Урманче һәм Мансур Хәсәнов бу тантананың иң абруйлы кунаклары буларак хөрмәтләнде. Мин бу сүзләрне аларның куанычтан балкыган йөзләрен күргән, шул тарихи тантананың шаһите буларак язам. Бу – булдыра алу шатлыгы иде.

Алгарак китеп булса да билгеләп узу кирәктер, бу ике шәхеснең үзара ихтирамлы мөнәсәбәтләре гомерлек булды. Еллар узып, инде Бакый Урманченың вафатыннан соң, аның бай мирасын саклау һәм республикабызның рухи тормышын баетуга куйган игелекле хезмәтләренә рәхмәтле булу йөзеннән бөек рәссамыбыз, даһи сынчыбызның музеен ачу,

шәһәребездә һәйкәлен кую буенча күркәм эшләре дә башкарылды. Әлбәттә, бу игелекле гамәлләр дә хөрмәтле Мансур Хәсәнов игътибарыннан, эшлекле теләктәшлегеннән башка эшләнмәде. Бу матур эшләрне оештыручыларга һәм башкарып чыгучыларга Бакый аганың җәмәгате Флора ханым, улы Айдар, туганнары һәм дуслары бик рәхмәтле булдылар.

Мансур Хәсәнов шәхес буларак күңелемдә гел үсә барды һәм аның белән аерым бер очрашу теләге дә көчәйде. Ә тормышыбызда зур үзгәрешләр чоры башланды, моңарчы күз алдына да китерә алмаган яңалык – «сүз иреге» – барлыкка килде. Халкыбызда милли рух баш калкытты, ул матбугатка үтте. Казанда да татар иҗтимагый үзәге оештыру буенча җыелып сөйләшүләр башланды. Ул хәрәкәт гел көчәйде һәм аның утырышлары Татар дәүләт академия театры бинасында, тулы залда уздырыла башлады. Күп таләпләр арасында иң мөһиме – республикага союздашлык статусы алу иде. Шул җыелышларда хөкүмәтебез вәкиле булып гел Мансур Хәсәнов катнаша һәм президиум өстәленең бер башында бик җитди кыяфәттә гел язып утыра һәм ахырында сүз алып бөтен куелган сорауларга җавап бирә, үз сүзен әйтә. Бик компетентлы булуы күпләрне сокландыра иде. Күңелемдә ул иң тәвәккәл хөкүмәт вәкиле булып калды. Мин боларны Татарстанда рәсми рәвештә беренче булып оешкан Түбән Кама Татар иҗтимагый үзәгенең рәисе һәм 1990–1995 елларда Татарстан Югары Советы халык депутаты буларак язам.

Менә шундый тынгысыз чорга туры килде Мансур ага Хәсәновның 60 еллык юбилее да. Шулай да мин якташлары исеменнән, Казанга килеп, кабинетында аны котлый алдым. Әңгәмә дә оешты. Б.Урманче белән Тукай-Кырлайга, Кышкарга, Мәчкәрәгә сәяхәт кылуыбыз, Карадуганда, абыем Бакый йортында кунак булуыбызны сөйләдем. Тукай-Кырлай комплексы өчен рәхмәтемне әйттем. Ә Б. Урманченың Түбән Камада «Җидегән чишмә» кичәсендә булуыннан инде ул хәбәрдар иде. Күрәсең, аңа бу турыда Аксакалыбыз үзе сөйләгәндер. Югыйсә, Мансур абый аптырабрак: «Азатҗан» син буласыңмыни инде ул?» – димәс иде. Чөнки мине бер Урманче гына шулай атады. Әңгәмәбезнең нәкъ шушы урынында миңа да Мансур Хәсән углын «Җидегән чишмә» кичәсенә чакырырга форсат туды һәм мин аңа «юбилеен туган авылы Бигештә дә, Түбән Камада да уздыру» – тәкъдиме ясадым. Мансур ага: «Сезнең ул чаралар рухи дөньябызда матур гына яңгыраш тапты, рәхмәт үзегезгә. Бәлки минекен дә булдыра алыр идегез, тик үтә дә тотрыксыз чор бит, кичереп торыйк» – диде. Кызганыч, тормыш гел катлаулана барды һәм без ул матур хыялны, Мансур Хәсәновны туган ягында да зурлау хыялын тормышка ашыра алмый калдык.

Ә шулай да безнең өчен шунысы куанычлы – илебездә башланган «үзгәртеп кору» сәясәте республикабыз үсешендә

дә яңа мөмкинлекләр тудырды. Шулар арасында Татарстан Фәннәр академиясен оештыру, мөгаен, аерым игътибарга лаеклыларның берседер. Киң эрудиция һәм зур оештыру сәләте таләп иткән бу эш Мансур Хәсәновка тапшырылды. Әлбәттә, бу очракта аның танылган галим, Казан университеты профессоры булуы да, башта өлкә комитетында, аннан соң Министрлар Кабинетында озак еллар Министрлар Кабинеты рәисенең урынбасары, беренче урынбасары буларак гел фән, мәгариф, мәдәният юнәлешләре эшчәнлеге өчен җаваплы хезмәттә булуы да исәпкә алынгандыр. Белгеч буларак та, оештыручы буларак та аның абруе төрле даирәләрдә һәрчак югары булды.

Республикабыз алдында торган үтә дә мөһим, катлаулы бу мәсьәләне дә Мансур Хәсәнов, үзенә хас җитдилек һәм җаваплылык белән лаеклы итеп башкарып чыкты. Сайлаулар үткәрелде һәм академик М. Хәсәнов, Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты буларак, аның уңышлы эшләп китүен тәэмин итте. Рәхмәт үзенә.

Тормышымда булып узган, хезмәтем белән бәйле, үзем өчен байтак ук мөһим булып исемдә калган бер вакыйганы искә алмасам, бу истәлекләр язмасы тулы ук булмас иде. Юк, үземә карата түгел, бигрәк тә, Мансур аганың бик җаваплы шәхес булуына карата. Көннәрдән бер көнне Министрлар Кабинетында республикабызда урнашкан эре завод, берләшмәләрдәге фәнни берәмлекләрнең эш нәтиҗәләрен барлау чарасы булып узды. Минем хезмәт биографиямдә беренче тапкыр булды бу, җитмәсә, бу чарага безнең генераль директор үзе дә барды. Күрәсең, күрсәтмә шулай булгандыр, чөнки утырышлар залында үземә таныш башка генераль директорлар да байтак иде. Шулай ук ул залда Мансур Хәсәнов барлыгын да шәйләдем. Ә утырышны премьер-министр үзе, Рөстәм Миңнеханов алып барды. Башлап казанлылар «хисап тотты». Башлаучыларга кыенрак, бигрәк тә республикакүләм мондый киңәшмәләрдә катнашканың булмаса. Монда да башлаучыларга: «Безне технология түгел, ә ирешелгән нәтиҗәнең кыйммәте кызыксындыра», – кебегрәк кисәтүләр ишетелде. Шуның өчен мин үз чыгышымны кыскарттым: кайсы завод, ничә патент алынган, ничәсе гамәлгә кертелгән һәм ничә миллион экономия алынганны сөйли башладым, әйбәт кенә китте. Зал җанланды, җиденче завод яңалыкларын әйтеп узгач, Рөстәм Нургалиевич: «Наверное, достаточно, Азат абый, кайда эш барганын без аңладык, все бы так работали, мы давно были бы в передовиках, молодцы», – диде. Көтелмәгән мондый борылыштан аптырап калдым, чөнки мин тәнкыйть көткән идем. Генераль директорыбызның кәефе дә әйбәт. Тәнәфестә мине М. Хәсәнов янына чакырдылар. Ул чыгышымның отышлы булуын әйтте һәм озакка сузмыйча үзенә рәсми басылган фәнни хезмәтләремнең исемлеген китерергә кушты. Шулай эшләдем дә. Мансур Хәсәнович фәнни

хезмәтләрем белән җентекләп танышып чыкты. Аннан патентларымның күплеген, безнең фәнни үзәкнең шундый зур берләшмә уңышларында әһәмиятле роль уйнаганын һәм шул хакыйкатьне хөкүмәт җитәкчесенең дә югары бәһаләвен ассызыклап үтте. Аннан: «Мин бит сине, Азатҗан, иҗтимагый өлкә хезмәткәре итеп кенә күрә идем», – дип куйды. Академиягә сайлауларда катнашырга өндәде. Шунда ук академиянең баш гыйльми секретаре Илдус Бариевич Хәйбуллинны чакырды һәм бергә эшләргә кушты. Бу үтә ихлас күңелле, җаваплы кеше миңа бик булышты. 2001 елгы сайлауларда катнашып, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы булдым.

Мансур Хәсән углы Хәсәнов эш кешесе иде. Ул бөтен барлыгын: акылын, сәләтен, энергиясен тормышыбызны матуррак, камилрәк итүгә багышлады. Бу фикер аның 75 яшьлек юбилеенда, Татарстан Фәннәр академиясенең актлар залында, Казан федераль университетында һәм бигрәк тә озак еллар партия, хөкүмәт эшләрендә бергә эшләгән, аралашкан, үзара дустанә мөнәсәбәттә булган хезмәттәшләренең ихлас чыгышларында бик еш яңгырады. Юбилярга үзләренең җылы хисләрен, рәхмәтләрен белдерергә омтылучылар бихисап булды ул көнне. Тантанада төрле елларда М. Хәсәнов белән республикабызның беренче җитәкчеләре буларак эшләгән мөхтәрәм Ф. Табиев, Г. Усманов, М. Шәймиев иптәшләр дә катнашты. Һәр өчесе үзләрен бик гади, кечелекле тотып, юбилярга карата иң җылы хөрмәтләү сүзләрен җиткерделәр. Бу Мансур аганың республикабызны, иң әүвәл аның фәнен, мәгарифен, мәдәниятен үстерүгә куйган биниһая хезмәтен тану иде. Бу аның хезмәттә үткән тормыш юлын бәһаләүнең, мөгаен, кульминация ноктасы булгандыр. Тышкы хисләргә саран, үтә дә тыйнак булуына карамастан, юбилярның йөзендә әлеге бәһадән канәгатьлек шәйләнә иде. Академия бинасында узган юбилей мохите үзе үк сирәк очрый торган дустанә халәт иде... Бүген күңелгә ирексездән шундый уй килә: ә академия бинасының икенче катында, гөлләр арасында, зәвыклы постаментта Мансур Хәсәновның җыйнак кына бюсты торса һәм башкалабызның бер урамына аның исеме бирелсә, бик урынлы булыр иде. Рәхмәтле була белик!

***Зыятдинов Азат Шәймулла улы,***
*техник фәннәр докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы*